Боерык

14 ноябрь 2013 ел № 348

**24.12.2010 кабул ителгән Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты №362 “Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүчеләр өчен конкурс үткәрү кагыйдәләрне раслау турында” (11.09.2013, №255 Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы редакциясендә) боерыкка үзгәртүләр кертү турында.**

Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнарына туры китерү максаты белән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты 24.12.2010 кабул ителгән №362 “Дәүләт гражданлык хезмәткә эшкә алу өчен конкурс үткәрү кагыйдәләрне раслау турында” (11.09.2013, №255 Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы редакциясендә) (моннан соң Боерык) боерыкка үзгәртүләр кертергә:

Боерыкның 1нче Кушымтасына:

1.6 пунктының 1.6.3 пунктчасындагы әлеге редакциядә бәян итергә:

«1.6.3. гражданлык хезмәткәрен яңа гражданлык хезмәткә билгеләгән чакта, 28 статьяның 2 бүлегендә каралган, 31 статьяның 1 бүлегендә каралган, 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән №79-ФЗ “Россия Федерация дәүләт гражданлык хезмәте” Федераль законы 60.1 статьяның 9нчы бүлегендә каралган”;

1.7 Россия Федерацииясе Президенты Указы белән расланган, хезмәт урыннары исемлеге» пунктындагы сүзләрне, “Дәүләт комитеты норматив акты белән расланучы хезмәт урыннары исемлеге,” сүзләренә үзгәртергә;

3.1 пунктын әлеге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Гражданлык хезмәткәре, гражданлык хезмәттә Дәүләт комитетында яңа эш урынына урнашу өчен, Дәүләт комитетының конкурсында катнашырга теләк белдерсә, ул Дәүләт комитеты Рәисе исеменә гариза яза;

4.4 пунктының 4.4.1 пунктчасында әлеге редакциядә бәян итергә:

4.4.1. Беренче этапта Дәүләт комитеты сайтында конкурска документлар кабул итү турында игълан ителә (3нче Кушымта), шулай ук конкурска бәйле әлеге мәгълүмат: гражданлык хезмәтендә вакантлы эш урыны исеме, претендентка карата таләпләр, гражданлык хезмәтен үтүчегә таләпләр, документлар кабул итү урыны һәм вакыты, документларны кабул итүнең соңгы көне, конкурсны алдан билгеләнгән үткәрү көне, конкурсны үткәрү урыны, конкурсны үткәрү тәртибе, башка мәгълүмат материаллары (4нче Кушымта). Конкурста катнашу, конкурста таләп ителгән документлар хакында игълан вакытлы матбугатта бастырыла.

Беренче этапта кандидатларны конкурска җәлеп итү мөһим, кирәкле документларны туплау һәм аларның таләпләргә туры килүен тикшерү.

Конкурсның беренче этабы Дәүләт комитеты сайтында яисә вакытлы матбугатта игълан бирү көненнән башлана, бәйгегә документлар кабул итү 21 көннән соң тәмамлана";

Пункт 1.2 раздела 1 Приложения 4 к Приказу изложить в следующей редакции Боерыкның 4нче Кушымтасының 1нче бүлегендәге 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.2. Гражданинга әлеге очракларда конкурста катнашу рөхсәт ителми:

1.2.1 аны хокукка таләпсез, эшкә сәләте чикләнгән, көчкә ия булган суд карары тарафыннан танылган очракта;

1.2.2. Моннан алда җәзага тартылуы, гаебе булу сәбәпле, дәүләт хезмәтендә эшли алмау, тулы көченә кергән суд хөкем карары нигезендә, шулай ук федераль закон нигезендә билгеләнгән алынмаган суд хөкеме аркасында;

1.2.3. федераль кануннар нигезендә сакланган  дәүләт серләре белән бәйле рөхсәт алу процедурасын үтүдән баш тарту, әгәрдә гражданин гражданлык хезмәтен башкаруы әлеге серләр белән бәйле икән;

1.2.4. медицина учреждениясе тарафыннын расланган, гражданлык

хезмәтен үтәүгә киртә ясаган авыру булуы;

1.2.5. гражданлык хезмәт күрсәтүченең яисә гражданлык хезмәткә яңа басучының якын туганнары (ата-ана, ирле-хатын, балалары, апасы, абыйсы, шулай ук ир яисә хатынның ата-анасы, абыйсы, апасы, балалары) белән әлеге хезмәткә турыдан-туры бәйләнеше булуы;

1.2.6. Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яисә башка дәүләтнең гражданлыгын алу очрагында;

1.2.7. Россия Федерациясе халыкара килешү нигезендә каралган, чит ил дәүләте (дәүләтләренең) гражданлыгы булган очракта;

1.2.8. Гражданлык хезмәткә басканда күрәләтә ялган мәгълүматлар һәм ялган документлар тапшыру;

1.2.9. Гражданлык хезмәткә басканда закон тарафыннан каралган мәгълүмат яки керем алу, милек һәм милеккә бәйле йөкләмәләр турында күрәләтә ялган мәгълүмат биргәндә;

2.1.10. 2004 елның 27 июленнән № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында», 2008 елның 25 декабереннән № 273-ФЗ "Коррупцияга каршы көрәшү турында" һәм башка коррупцияга каршы көрәшү федераль кануннар белән билгеләнгән, гражданлык хезмәткәргә карата эшкә яллаучы тарафыннан ышаныч югалту, чикләмәләрне истә тотмыйча эш итү, карашлар конфликтларын җайга салмау, вазифаларны үтәмәгән очракта;

Боерыкның 5нче кушымтасы 7 пунктында "(форма 086-У)" сүзләрен әлеге җөмлә белән алыштырырга - "Российской Федерации Хакимияте федераль башкарма власьте вакәләте тарафыннан билгеләнгән форма буенча".

2. Әлеге боерык аның рәсми нәшер ителү көненнән тулы көчкә ия.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис М.Р. Зарипов